КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 октябрь г.Казань № 904

Муниципаль район составына керүче җирлекләрнең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен тигезләү буенча муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу һәм муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертларның башка рәвешләрен бирү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Муниципаль район составына керүче җирлекләрнең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен тигезләү буенча муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу һәм муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына бюджетара трансфертларның башка рәвешләрен бирү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карар 2020 елга (2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына) бюджетлардан башлап, Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга:

«Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга аерым субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2007 ел, 31 август, 427 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга аерым субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2007 ел, 31 август, 427 нче карары белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга аерым субсидияләр бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 15 ноябрь, 889 нчы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                 А.В.Песошин